# Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге составына керүче Телэнче-Тамак авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
# КАРАР

22 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 15, 17, 22, ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Телэнче Тамак авыл җирлеге Телэнче-Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- хоккей кортын ремонтлау
- Телэнче-Тамак авылы мәдәният йорты территориясен яшелләндерү
- Телэнче-Тамак авылында Сабантуй милли бәйрәмен оештыру өчен бүләкләр сатып алу;
-Телянче-Тамак авыл мәдәният йорты территориясендә балалар мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру(2 этап);
- Телэнче-Тамак авылы зираты территориясендә куаклар кисү;
- Телэнче-Тамак авылы мәдәният йорты янындагы гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы ***810*** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **434** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **434** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Телэнче Тамак авыл җирлеге Телэнче-Тамак авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.
2. «2023 елда яшәү урыны буенча Телэнче Тамак авыл җирлеге Телэнче-Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз ) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек